**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**СОВЕТ КОРСАБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

422051, Республика Татарстан, Сабинский район,
с.Корсабаш, ул. Школьная, д. 28
тел. (84362) 2-27-49

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КУРСАБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422051, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Курсабаш авылы, Школьная урамы, 28 йорт
тел. (84362) 2-27-49

e-mail: korsab.sab@tatar.ru

---

РЕШЕНИЕ
23.10.2024

КАРАР
№21

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге Советының 18.02.2022 №6 карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

РФ Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 05.02.2024 ел, №124 карары кабул ителүгә бәйле рәвештә, Саба муниципаль районының Курсабаш авыл җирлеге Советы

Карар кылды:

1.Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында Нигезләмәне раслау хакында» 18.02.2022 ел, №6 карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.7 пунктының 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) планлаштыру структурасы элементлары (зоналар (массивлар), районнар (шул исәптән торак районнар, микрорайоннар, кварталлар, сәнәгать районнары), яр буйлары, гражданнар үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яисә яшелчәчелек алып бара торган территорияләр;»

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча рәсми рәвештә халыкка җиткерергә: http://pravo.tatarstan.ru.

Курсабаш авыл җирлеге башлыгы А. Р. Гыймадиев